МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.04.2026 Казан ш. № 11-58

«Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиясе турында" Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.05.2016 ел, № 11-60 боерыгы белән расланган Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

«Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиясе турында" Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.05.2016 ел, № 11-60 боерыгы белән расланган Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 21.03.2018 ел, № 11-35, 07.04.2023 ел, № 11-28, 28.08.2023 ел, № 11-92, 20.06.2024 ел, № 11-50, 25.03.2025 ел, № 11-51, 20.06.2025 ел, № 11-114 боерыклары белән расланган) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия Министрлык боерыгы белән төзелә. Министрлык боерыгы белән Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре билгеләп куела һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

2.2 нче пунктның "а" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) министрның беренче урынбасары – министрлыкның Казначылык департаменты директоры (Комиссия рәисе), Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (Комиссия рәисе урынбасары), Министрлыкның кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (алга таба – Министрлыкның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы заты) (Комиссия секретаре), Министрлыкның кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы, Министрлыкның юридик бүлеге башлыгы һәм Министрлыкның министр билгели торган башка бүлекчәләрендәге дәүләт хезмәткәрләре;»;

3.1 нче пунктның «а» пунктчасындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәдә каралган белешмәләрнең дәүләт хезмәткәре тарафыннан дөрес бирелмәве яисә тулы күләмдә бирелмәве турында;»;

3.1 пунктның "б" пунктчасындагы беренче абзацында “кадрлар бүлегенә” дигән сүзләрне “кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә” дигән сүзләргә алмаштырырга;

3.2 пунктта “кадрлар бүлегенә” дигән сүзләрне “кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә” дигән сүзләргә алмаштырырга;

3.5 пунктның «б» пунктчасында “кадрлар бүлегенә” дигән сүзләрне “кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә” дигән сүзләргә алмаштырырга;

3.11 пунктның "а" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт граждан

хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмә буенча дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөрес һәм тулы булып торуын билгеләргә;»;

3.31 пунктта “кадрлар бүлеге тарафыннан” дигән сүзләрне “кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге тарафыннан” дигән сүзләргә алмаштырырга.

Министр М.Ж.Фәйзрахманов